*Һәр көнебез нәтиҗәле булсын!*

**Декабрь 2018 ел**

# Яңа көн

**Олы Елга мәктәбенең укучылар иҗади мәгълүмат үзәге газетасы**

## Төп яңалыклар

Матур тарихыбыз булган яшьләр оешмасы— комсомолның зур юбилее– 100 еллыгы уңаеннан мәктәптә комсомол оешмасының актив әгъзалары белән бик җылы һәм кызыклы очрашу булып үтте









6 нчы декабрьдә мәктәптә гомуми ата-аналар җыелышы булды.Ата-аналар җыелышында ГИБДД вәкилләре дә катнашты . .Алар ата-аналарны кирәкле һәм әһәмиятле мәгълумат белән таныштырдылар, сорауларга тулы һәм аңлаешлы җаваплар бирделәр

Халыкара коррупциягә каршы көрәш көне уңаеннан 6 нчы декабрь көнне барлык сыйныфларда да шушы темага багышланган сыйныф сәгатьләре булып узды.Сыйныф җитәкчеләре укучыларга коррупция төшенчәсенең асылын аңлаттылар. Укучылар кирәкле һәм файдалы мәгълумат алдылар.



# Яңа ел бәйрәмен кайда ничек үткәрәләр?!



**Германия** Германиядән башлыйк, Яңа ел чыршысын бизәү традициясе нәк менә Германиядә уйланып табылган. Сүз уңаенда, анда бу традиция урта гасырларның ерак заманнарында ук барлыкка килгән. Немецлар фикеренчә, Санта Клаус ишәктә йөри, шуңа күрә башмакларга балалар аны сыйлау өчен печән сала.



**Швеция** Ә менә Швеция дөньяга беренче пыяла чыршы уенчыкларын бүләк итте (19 гасырда). Анда яңа елга йортлардагы утларны сүндермәскә һәм урамнарны яктыртырга кабул ителә-бу чын ут бәйрәме.




**Англия** Англиядә Яңа елга Борынгы Инглиз әкиятләренең сюжетларына балалар өчен тамашалар уйнаталар. Лорд чуалышлар үзе артыннан күңелле карнавал йөреш алып бара, анда әкият персонажлары: Хобби Хорс, Март куяны, Шалтай-Болтай, Панч һ.б. катнаша. Яңа ел төнендә урам сәүдәгәрләре уенчыклар, сызгыргычлар, азык-төлек, битлекләр, һава шарлары саталар.



**Америка** Американлылар өчен яңа ел, Times Square 00: 00 күрсәткәч башлана. Бу вакытта меңләгән кеше автомобиль гудогына баса. Ә калган кешеләр моны аңлый - менә ул Яңа ел. Традицион ашамлык кара борчактан тотынырга була. Нәкъ менә ул уңыш китерә дип санала



**Франция** Француз Кыш бабае-Пер Ноэль-Яңа ел төнендә килә һәм балалар башмакларында бүләкләр калдыра. Яңа ел пирогынада пешкән борчак эләккән кеше"кузак короле" титулын ала һәм бәйрәм төнендә барысы да аның боерыкларына буйсына



## Ә сездә ничек үтә Яңа ел бәйрәме?

*Шушы сорау белән Эльвира мөрәҗәгать итте:*

-Әлфия апа,сез яна ел бәйрәмен яратасызмы?
—Яратам,бик яратам.
—Ә өегезне бизәргә өлгердегезме соң әле?
—Юк,тиздән бизим инде,
—Яна елны кем белән каршы алачаксыз?
—Гаиләм белән.
—Апа,сезнен "фирменный" ризыгыгыз нинди?
—Каз,алмалар һәм кара җимеш белән.

-Риф Абый,сез кыш бабайга ышанасызмы? Э Кыш бабайдан нәрсә сорадыгыз ?
-Конечно ышанам , Ёлка сорадым.
-Фирменный ризык нинди була сездә?
-Оливье инде ,Яна елда шул ,зур каз,юк урдэк булыр наверно .



-Эльвира апа,Яна елны яратасызмы?
-Яратам
-Кыш бабайга ышансызмы сон?
-Эйе,ышанам
-Нэрсэ сорадыгыз Аннан
-Секрет инде бусы,а то не сбудется.
-Э нинди ризыклар пешерэсез?
-Каз кыздырам, торт пешерэм,салатлар ясыйм .

## Яңа ел йолдызнамәсе

**



**Кучкар** .Гаилә мөнәсәбәтләренең салкынаю куркынычы бар. Сабыррак булыгыз, бер-берегезгә юл куярга тырышыгыз.

**Үгезбозау.**Гаилә тормышы үз чираты белән бара. Мәхәббәтен эзләүчеләрне кызыклы очрашулар көтә. Инициативаны үз кулыгызга алудан курыкмагыз.

**Игезәкләр.** Сөйгән ярын эзләүчеләр активлыкны киметмәскә тиеш. Кунакка йөрегез, күбрәк аралашыгыз.

**Кысла.**Яраткан кешегез еракта яшәсә, тиздән шул якларда булачаксыз. Бәйрәм бик кунелле үтәчәк.

**Арыслан.**Мәхәббәт өчен ике кешенең уртак кызыксынулары булу мөһим. Командировкага чыгучыларның юлы уңа.

**Кыз.**Яңа мөнәсәбәтләр артык тәвәккәл адымнарны яратмый. Финанс мәсьәләсен хәл итү өчен уңайлы вакыт.

**Үлчәү.**Шәхси тормышта бар да яхшы. Тормыштагы активлыкны киметмәгез. Алда сезне кызыклы мөмкинлекләр көтә.

**Чаян.** Эштә үзгәрешләр юк. Бурычлардан котылырга тырышыгыз. Гомумән, акчаны сак тотарга кирәк.

**Укчы.**Сүзегезне үлчәп кенә сөйләгез. Мөмкинлек тапсагыз, ял алыгыз, кая да булса барып, җилләнеп кайтыгыз.

**Кәҗәмөгез.**Реалист булырга кирәк. Күктән җиргә төшәргә вакыт. Эштә күптәннән уйлап йөргән планнарны тормышка ашыру мөмкинлеге туачак.

**Сукояр.**Аралашу даирәсен киңәйтергә кирәк. . Яңа эш башлау өчен кулай вакыт.

**Балык.**Барысы да үзегездән тора. Парын эзләүчеләр үзенә кулай кешене үз тирәсеннән, эштә яки укуда таба алачак.

## Кыш бабайдан кем нәрсә көтә?!

Сәлам , Фирдус ,Син Яна елны котэсенме?
-Әйе, әлбәттә!
-Кыш бабайга ышанасынмы?
-50/50 ?
-Кыш бабайданнэрсэ сорадын?
-Квадроцикл, я не мелочусь
-Алып килер дип уйлыйсынмы?
-Юк элбэттэ! Ул мина конфет алып килэк!!

-Сәлам, Динара  Кыш бабайдан нәрсә сорадын?
-Сочига билееееееет!!!
-Хыялларың тормышка ашсын Динара!

-Сәлам Чулпан ,хәлләрен ничек ?
-Яхшы !
-Чулпан син кыш бабайга ышанасынмы?
-Әйе!
-Нәрсә сорадын?
-Зууур курчак
-Ярар Чулпан, киләчәк яна ел белән сине!

-Фәннур,сәлам, Кыш бабайдан нәрсә сорадын
-Lexus's сорадым
-Алып килер дип уйлыйсынмы?
-Элбэттэ! Тошемдэ
-Ярар. Фәннур, хыялларын чынга ашсын!

*Әңгәмәне Сиринә алып барды.*

## Кадерле дуслар!

Җир өстенә аклык-пакьлек алып килгән Яңа ел бәйрәме котлы булсын! Киләсе елның 365 көне дә бәхет-шатлык кына китерсен. Аткан таңнарның барысы да алсу булсын. Тормыш юлларында шатлыклы очрашулар, бәхетле елмаюлар, куанычлы мизгелләр күп булсын!

Яңа елга беренче адым изгелек булсын.
Якынлашып килүче Яңа ел белән сезне!
Яңа еллар килсен бәхет алып,
Яңа еллар килсен елмаеп,
Күңелләрдә мәңге шатлык булсын,
Яшәмәгез дуслар моңаеп.
Яңа ел котлы булсын,
Дөньялар тыныч торсын!

Газетаны әзерләделәр: Насибуллина Сиринә, Камалова Эльвира, Шайхутдинов Данис, Галиуллин Ислам, сыйныф җитәкчесе Сибгатуллина Рушания










## ***Без алар белән горурланабыз!***

Укучыларның бөтенроссия һәм республика олимпиадасының муниципаль этабында җиңү яулаган укучыларыбызны котлыйбыз, аларга алга таба да уңышлар телибез.



Гиниятов Булат– астрономия фәне буенча җиңүче; физика һәм география фәннәреннән призер.

Сибгатуллин Рифат - биология фәненнән җиңүче.



Минязов Нияз,Шайхутдинов Әмир, Хасанова Язилә—математика фәне буенча призерлар.









Валеев Булат, Гилазов Инсаф –технология фәне буенча призерлар.







Абдуллина Ләйсән һәм Ахмадеева Диләфрүз –инглиз теле фәне буенча призерлар.

Галеева Язилә –тормыш иминлеге нигезләре фәне буенча призер

